РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» март 2023 ел г. Альметьевск № 55

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башлыгының норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 1 апрелендәге 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 1 апрелендәге 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтаның 5 нче бүлегендә:

5.4 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Рәисенең еллык юлламасы белән билгеләнгән Татарстан Республикасы законнарын үстерүнең төп юнәлешләре;»;

5.4 пунктының җиденче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция Суды» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны аппарат җитәкчесе Р. Е. Әфләтуновага йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы Т.Д. Нагуманов